КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 февраль г.Казань № 96

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү һәм Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планын раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 58 статьясы һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 3 өлешенең 43 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә һәм аның составы;

2025 елга Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 18 февраль, 96 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 58 статьясын һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 3 өлешенең 43 пунктын үтәү максатларында Татарстан Республикасы гражданнарына һөнәри юнәлеш бирү чараларын гамәлгә ашыру максатларында төзелде.

1.2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Комиссия даими эшләүче коллегиаль киңәшмә орган булып тора, үз эшчәнлеген Комиссия әгъзаларының тигез хокуклылыгы һәм кабул ителә торган карарларның хәбәрдарлыгы принципларында төзи.

1.4. Комиссия составына хезмәт базарында конкуренциягә сәләтлелекне тәэмин итү максатларында республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе), «Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге, эшчәнлекләре гражданнарның, шул исәптән яшьләрнең һөнәри компетенцияләрен үстерүгә юнәлдерелгән автономияле һәм бюджет оешмалары вәкилләре керә.

Комиссия утырышларында кызыксынган оешмалар вәкилләренең катнашуы, аның составына кермичә, Ведомствоара комиссия рәисе (рәис урынбасары) чакыруы буенча мөмкин.

## II. Комиссиянең бурычлары һәм хокуклары

2.1. Комиссиянең бурычлары түбәндәгеләр була:

республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары, Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча эш бирүчеләр эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү буенча өстенлекле юнәлешләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча килештерелгән карарлар әзерләү;

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш буенча чараларның еллык планына тәкъдимнәр булдыру;

узган ел өчен Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап карау;

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру чараларын гамәлгә ашыру механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү системасын үстерүгә кагылышлы башка мәсьәләләрне карау.

2.2. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Комиссия утырышларына Комиссия составына керми торган органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларын һәм белгечләрен (экспертларын) чакырырга һәм тыңларга;

республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары, Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча мәгълүматны эш бирүчеләрдән сорарга;

## III. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

3.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Комиссия түбәндәге составта төзелә: Комиссия рәисе, Комиссия рәисенең ике урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм Комиссия секретаре.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

Комиссия әгъзалары эш барышында үзләренә мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга таратырга хокуксыз.

Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен иҗтимагый башлангычларда башкара.

3.2. Комиссия эше утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла, алар турыдан-туры катнашу форматында яисә видеоконференция элемтәсе форматында үткәрелергә мөмкин.

Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендәярты елга бер тапкыр уздырыла.

3.3. Комиссия рәисе тарафыннан Комиссия әгъзаларының читтән торып тавыш бирү юлы белән комиссия утырышын читтән торып уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.

3.4. Комиссия утырышын читтән торып тавыш бирү юлы белән читтән торып үткәрү турында карар кабул иткәндә, Комиссия секретаре Комиссия утырышын үткәрү көненә кадәр өч эш көннән дә соңга калмыйча, Комиссия утырышының көн тәртибен һәм Комиссиянең рәисенә, читтән торып тавыш бирүгә чыгарылган һәр мәсьәлә буенча язма рәвештә фикер бирү сроклары турында мәгълүматны җиткерә.

3.5. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

3.6. Комиссия әгъзалары шәхсән үзләре тавыш бирә. Аларга үз вәкаләтләрен башка затларга бирү рөхсәт ителми.

3.7. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының исемлек санынnan яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

3.8. Комиссия тәкъдимнәре  Комиссия әгъзалары биргән тавышның күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

3.9. Комиссия тәкъдимнәре  беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана.

3.10. Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия әгъзаларына, шулай ук Комиссия составына кермичә генә рәис (рәис урынбасары) чакыруы буенча Комиссия утырышында катнашкан кызыксынган оешмалар вәкилләренә Комиссия утырышы уздырылганнан соң 10 эш көне эчендә җибәрелә.

3.11. Комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тоту Комиссия рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 18 февраль, 96 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, комиссия рәисе |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Федоров Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының һөнәри белем бирү идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Тонконог Софья Львовна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һөнәри укыту һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге башлыгын, Комиссия секретарен |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гарипов Ленар Наил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |
| Гыймаев Илшат Сәхап улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Ислаев Василий Филиппович | «Студентларның хезмәт отрядлары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары |
| Кузьмичева Елена Ивановна | «Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сабирова Айгөл Азат кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |
| Халиков Тимур Рафаэль улы | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Шувалова Диләрә Данияль кызы | «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 18 февраль, 96 нчы
карары белән расланды

2025 елга Татарстан Республикасында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү чаралары планы

| Т/с | Чаралар исеме | Чаралар уздыру чоры | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын үткәрү | 2025 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 2 | «Мәктәп бизнес-стартлары» республика проектын үткәрү | 2025 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3 | «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион эшләүче яшьләр иҗаты фестивален үткәрү | 2025 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4 | «Ел инженеры» республика конкурсын уздыру | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 5 | «Россия эше. Мөмкинлекләр вакыты» бөтенроссия эшкә урнаштыру ярминкәсен оештыру | 2025 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 6 | Төзелеш тармагында «Һөнәре буенча иң яхшы» конкурсын үткәрү | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7 | Халыкара төзелеш чемпионатын оештыруда катнашу | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 8 | Һөнәри белем бирү оешмаларында ачык ишекләр көннәре үткәрү | 2025 елның I – II кварталлары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 9 | «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының төбәк этабын һәм Татарстан Республикасының Югары технологияләр чемпионатын үткәрү | 2025 елның I – II кварталлары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 10 | Инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» төбәк чемпионантын үткәрү | 2025 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, тармак министрлыклары |
| 11 | «Агробуын» балалар һәм яшьләр арасында авыл хуҗалыгы һөнәрләрен популярлаштыруның озак сроклы максатчан проектын гамәлгә ашыру | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| 12 | Татарстан Республикасы вәкилләренең Мәскәүдә «Һөнәрләр фестивале» чарасында катнашуы | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, тармак министрлыклары |
| 13 | «Яшьләр эше» республика яшьләр форумын үткәрү | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |

_______________________________________________